# Даплы авылдашларым




Быел Бөек Ватан сугышы беткәнгә 67 ел. Ә сугыш үзенең ачлыгы-ялангачлыгы, мәрхәмәтсезлеге белән күңелләрне әле дә өшетә. Җиңү көне җиңел бирелмәде! Безгә җиңү бүләк иткән авылдашларыбыз даны мәңге сакланыр…

# Исәннәрнең кадерен белик…



Каримов Хәбир абый 1925 нче елда Шекә авылында туа. 1943 елның 25 январенда авылдашы Ризванов Мөхәммәтҗан белән бергә сугышка чыгып китә. Снайпер булып Балтыйк буе фронтында хезмәт итә. 1944 елның 31 январенда бик каты яралана.Уң аягын кисәргә туры килә.8 ай буе госпитальләрдә дәвалана. 1944 елның сентябрендә култык таяклары белән, Арча белән ике араны 2 көндә узып, Шекәгә, туган йортына кайтып төшә. Гаилә кора. Бүгенге көндә улы Хәниф гаиләсе тәрбиясендә матур гына гомер итә.

# Исәннәрнең кадерен белик…



- Ризванов Мөхәммәтҗан 1925 елда Шекә авылында туа. Сугыш башланганда аңа 16 яшь була. Сугышка 1943 елда алына. 1944 елда каты яраланып, госпитальгә эләгә. Документлары югалу сәбәпле, өенә хәбәрсез югалуы турында хәбәр килә. 1944 елның октябрендә Шекә авылына кайтып төшә. 1947 елда Ташкичү кызы Рәхимә апа белән тормыш кора.Алар бүгенге көндә дә тигез, матур тормыш кичерәләр, уллары Рифат гаиләсе тәрбиясендә яшиләр.





# Үлгәннәрнең каберен белик…

Фатхрахманов Зәкәрия абый, I дәрәҗә дан ордены, “За оборону Ленинграда”медале, Кызыл йолдыз ордены лауреаты.

1934-36 елларда армиядә, 1939 елда-Фин сугышында, 1941 -1944 елларда Бөек Ватан сугышында була.



- Габдрахманов Әфләтун абый 1925 елда туа. 1943 елда сугышка китә. 1945 елның августында Кытай җирендә барган сугышта да катнаша. 1946 елның октябрь аена кадәр Харбин шәһәрендә була. 1946 елда исән-сау килеш туган якларына кайта. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен «Ватан сугышы» орденына һәм медальләргә ия була.



- Бәширов Кәрим абый 1925 елда туа. 1943 елның 10 январенда сугышка чыгып китә. Аларны Арчадан Ерак Көнчыгышка озаталар. Манчжурия җирендә каты сугышлар була. Авыр контузия алып, госпитальгә эләгә. Дәваланып чыккач, Харбинны алуда катнаша. 1950 елда демобилизацияләнеп, авылга кайта. Шекә мәктәбенә укытырга килә һәм шушында төпләнеп кала. Хатыны Халидә апа белән 5 бала тәрбияләп үстерә. 2007 елда вафат булды.



# Камалов Гарапша абый.

1943 елның 9 октябрендә 17 яшендә сугышка китә. Сугышта шофер, танкист була. Германиянең Дрезден шәһәренә кадәр барып җитә. Сугышчан бүләкләре бар. Бүгенге көндә вафат.



- Хабибрахманов Рөстәм абый. 1943 елда сугышка китә. Мариенбург шәһәрен азат иткәндә каты яралана һәм 1945 елда авылга кайтып төшә. Батырлыклары өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнгән. 2008 елда вафат булды.



Василов Фәрит абый.
1943 елда сугышка алына. Берлинга кадәр барып җитә. Мина шартлап аягы нык имгәнә. Сугыштан исән кайта, ләкин яралары гомер буе әрни. Бүгенге көндә вафат.



Мәрдәнов Гыйният абый, 1921 елда туа, 1942 елның мартында сугышка китә, яраланып аягын тубыктан кистерә, тыныч тормышта озак еллар күмәк хуҗалыкта эшли. Бүгенге көндә вафат.



Гайнетдинов Ибраһим абый 1916 елда туган. 1941 елның көзендә сугышка китә. Сугыш вакытында күрсәткән батырлыклары өчен орден һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә. Бүгенге көндә вафат.

# Нуриев Әсгать Нурмөхәммәт улының сугышчан юлы



Әсгать  абыйның сугышчан бүләкләре:
“За боевые заслуги” медале,
II-III дәрәҗә дан орденнары,
“Отечественная война” ордены,
“Участник операции “Нева””билгесе,
“СССРның кораллы көчләренә 60 ел ” медале,  “Җиңүгә 40 ел” медале,
“Ленинград блокадасы участнигына”,
“Невский плацдарм ”билгесе,
“  28 миномет Ленинград бригадасы ветераны” ветеран значогы





Әсгать абый сугышчан дуслары, аларның туганнары белән очрашуда, 1999 ел.




# Нуриев Әсгатьнең сугышчан юлы
# 1942-1947

Бүген без үлгәннәрне хөрмәт белән искә алабыз, рухларына дога кылабыз, исәннәрне кадерлибез, чөнки бүген- Бөек җиңү бәйрәме. Бәйрәм көнендә генә түгел, һәркөн тоеп яшәсеннәр иде алар безнең хөрмәтебезне, картлыклары тыныч һәм бәхетле булсын , дип телибез...